
НУРЗИЯ СЕРГЕЕВА

# ТЫЛСЫМЛЫ БИЗӘК


# МАГИЯ УЗОРА



ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО

НУРЗИЯ СЕРГЕЕВА

# МАГИЯ УЗОРА



Казань
Татарское книжное издательство
2017

НУРЗИЯ СЕРГЕЕВА

# ТЫЛСЫМЛЫ БИЗӘК



Казан
Татарстан китап нәшрияты
2017

УДК 746
ББК 37.248
С36

Рәссамнары: Нурзия Сергеева, Станислав Сергеев
Художники: Нурзия Сергеева, Станислав Сергеев

Тышлыкта: «Беренче канал»дагы «Голос. Дети-2» телевизион проекты финалисты, Казан шәһәренең 4 нче гимназия-интернаты укучысы Сәидә Мөхәммәтҗанова.

На обложке: Саида Мухаметзянова – финалистка телевизионного проекта «Первого канала» «Голос. Дети-2», ученица гимназии-интерната № 4 города Казани.

Сергеева, Н. Г.

С36 Тылсымлы бизәк = Магия узора / Нурзия Сергеева. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2017. – 56 б.

ISBN 978-5-298-03527-9

Китапның авторы үз укучыларын татар декоратив-гамәли сәнгате, шул исәптән милли бизәкләр төшерелгән күн эшкәртү, чигү, зәркәнчелек, балчык эшкәртү, каллиграфия һ. б. төрләре белән таныштыра. Шулай ук әлеге китапта түбәтәй, калфак тегү серләренә төшенә аласыз.

Китап кул эшләре белән кызыксынучыларга багышлана.

Автор книги знакомит читателей с татарским декоративно-прикладным искусством, в частности с национальным орнаментом, который проявил себя в кожаной мозаике, вышивке, ювелирном исскустве, керамике, каллиграфии и т. д. Также здесь представлены мастер-классы по изготовлению калфака, тюбетейки.

Книга предназначается всем тем, кто интересуется татарским прикладным искусством.

УДК 746
ББК 37.248

ISBN 978-5-298-03527-9

© Татарстан китап нәшрияты, 2017
© Сергеева Н. Г., 2017

## КЕРЕШ

Кешеләр борын-борыннан үзләрен эстетик ләззәт бирә торган әйберләр белән уратып алырга тырышканнар. Татар декоратив сәнгате, талантлы һөнәрчеләр тарафыннан камилләштерелеп, гадәти тормышка матурлык өсти торган эшчәнлеккә әйләнә. Күп кенә бизәкләр, бизәнү әйберләре, беренче чиратта, магик төсмер бирелеп, кешеләрне явыз рухлардан саклый торган бөти булып хезмәт итә.

Болгар-татар сәнгате электән үк дөнья дәрәҗәсенә күтәрелгән була. Татар осталарының эшләре формалары, бизәкләренең матурлыгы, төсләре, сәнгати кыйммәте ягыннан югары бәяләнә. Аларда табигать белән бәйләнеш тә, дини, тарихи гореф-гадәтләр дә чагылыш ала.

Милли киемнәрдә, йорт эчендә кулланыла торган сөлге, кашага, тастымалларда чигелгән үсемлек орнаментлары югары дәрәҗәдә сәнгатьчә башкарылган һәм кабатланмас үзенчәлеккә ия. Татар чигүен еш кына «энә белән ясалган рәсем» дип атаганнар, чөнки чигүләр картиналар ролен үтәгән. Чигүнең кычкырып торган бизәкләрен бай үсемлекләр патшалыгы белән чагыштырып була, анда лалә белән гөлчәчәкләр дә, чалма чәчәк белән канәферләр дә, ромашка белән мәкләр дә тоемлана. Аларга карагач, күңел ачыла, кәефләр күтәрелә.

Татар хатын-кызларына шома чигү һәм сәйлән белән чигүдә, элмәләп чигүдә һәм тырнак алмалауда тиңнәр булмый. XIX гасыр башында популярлык казанган алтын белән чигү татар чигүен кустарьчылыктан югарырак дәрәҗәгә күтәргән.

Зәркәнчелектә, металл эшкәртүдә дә зур осталыкка ирешкән һөнәрчеләребез. Чылтырап торган озын алкалар, авыр чәч чулпылары, көмеш җепләрне үреп эшләнгән яка чылбырлары, хәситәләр, брошкалар, беләзекләр кемне генә битараф калдырыр икән? Татар осталары, зәркән эшләнмәләрен эшкәрткәндә, төрле ысулларны куллана белгәннәр: кою, чүкү, уеп бизәкләү, басма, көмеш каралту, ташлар белән бизәү дисеңме... Арасыннан иң кыйммәтлесе яссы һәм төерле бизәк төшереп эшләнгәннәре булган.

Гамәли сәнгатьтә туку зур урын алып торган. Махсус агач станнарда тастымаллар, җаймәләр, паласлар тукыганнар. Иң киң та-

## ВВЕДЕНИЕ

Издревле люди старались окружить себя предметами, несущими эстетическое наслаждение. Татарское декоративное искусство, созданное талантливыми мастерами, охватывает все виды художественной деятельности, вносящие красоту в обыденную обстановку. Многие узоры и украшения создавались в виде оберегов.

Булгаро-татарское искусство ещё в далёком прошлом взошло на мировой уровень. Произведения татарских мастеров ценились за их высокие художественные качества, гармонию формы, красоту орнамента и расцветки. В них ощущается связь с природой, отражаются традиции, история, религия.

Высокими художественными достоинствами и самобытностью отличается вышивка, которая активно использовалась в национальной одежде и внутреннем убранстве жилища. Татарскую вышивку зачастую называли «живопись иглой», так как вышитые изделия выполняли функцию картин. Яркие и жизнерадостные узоры вышивок можно сравнить с богатейшим растительным царством, в котором угадываются элементы роз и тюльпанов, пионов и гвоздик, ромашек и маков.

Татарские женщины в совершенстве владели вышивкой гладью и бисером, тамбурным швом и ушковой техникой. В начале XIX века получившее широкое распространение золотое шитьё подняло татарскую вышивку из кустарного ремесла на более профессиональный уровень.

Непревзойдённого мастерства достигли татарские мастера в ювелирном искусстве и художественной обработке металла. Никого не оставят равнодушным длинные серьги и тяжеловесные накосники («чулпы»), изящные воротниковые подвески («яка чылбыры») и своеобразные нагрудные перевязи («хаситэ»), разнообразные броши и браслеты («белэзек»). Татарские мастера умело владели различными приёмами изготовления и средствами орнаментации ювелирных украшений: литьё, чеканка, гравировка, штамповка, чернение, инкрустация самоцветами. Наиболее ценные украшения изготовлялись в трудоёмкой технике зерни и бугорчатой скани.

Большое место в прикладном искусстве занимало ткачество. На специальных дере-

ралган туку ысуллары дип чүпләмле туку, төсле чүпләм, асалап сугу саналган. Күбрәк геометрик бизәкләр кулланылган, сирәк булса да, чәчәк, зооморф мотивлар очрый.

Татар декоратив-гамәли сәнгатенең үзенчәлекле төрләреннән берсе – күн мозаикасы. Идел буе болгар һөнәрчеләре күнне вак кисәкләрдән тоташтырып эшкәртү технологиясен уйлап тапканнар. Бу, бер яктан, күнне әрәм-шәрәм итмәс өчен булса, икенче яктан, кабатланмас, уникаль эшләнмәләр барлыкка китерергә ярдәм иткән. Бу ысул белән эшләгәндә, күн кисәкләре берьюлы берничә читеккә киселгән. Фрагментлар күнне бер-берсенә якын китереп, су кермәслек итеп, махсус җөй белән ефәк җепләр ярдәмендә тоташтырылган. Башка халыкларда күнне болай итеп эшкәртү очрамый.

Гамәли сәнгатьнең иң борынгы төрләренә керамиканы, балчыктан яндырып эшләүне кертәләр. Шулай булса да, керамика үзенең иң югары ноктасына Болгар һәм Алтын Урда чорында ирешә.

Ислам кабул ителү һәм гарәп әлифбасының кулланылышка керүе белән, татар язмачалыгы традицияләре барлыкка килә, дини характердагы картиналар – шәмаилләр ясау үсеш ала. Татар шәмаилләрендә Коръән сүрәләре һәм хәдисләр файдаланыла. Шәмаилләр һәр мөселманның өендә ишек өстенә йә, Кәгъбәгә каратылып, диварга эленә.

Татар декоратив гамәли сәнгатенең һәркемгә таныш тагын бер төре – татар костюмы. Киемдә, берсен берсе тулыландырып, гамәли сәнгатьнең берничә төре кулланыла: төрле чигешләр, туку, зәркән элементлары һәм күн мозаикасы. Киемнең матурлыгы, аның фасоны, костюм ансамблен барлыкка китерә торган предметлар белән дә бәйле. Бүгенге көндә без милли киемгә музей экспонаты итеп кенә карамыйбыз. Ул тулысынча яки аның аерым өлешләре көндәлек тормышта да кулланыла. Баш киеме белән костюм тулы ансамбльгә әйләнә, аны тагын да матурайта, затлы итә.

вянных станках ткались полотенца, коврики, паласы. Традиционными способами ткачества являлись бранный («чуплэмле туку»), выборный («тосле чуплэм») и закладной («асалап сугу»). Орнаментация приобретала в основном геометрический характер, но встречались и цветочные, зооморфные мотивы.

Своеобразным видом декоративно-прикладного искусства татар является искусство кожаной мозаики. Волжскими булгарами разработана собственная уникальная технология выделывания кожи и изготовления мозаичной обуви, позволяющая получать неповторимые изделия и безотходное производство. Узор вырезался одновременно для нескольких сапог. Фрагменты сшивались шёлковыми нитями встык декоративным, не пропускающим влагу швом.

К древнейшим видам прикладного искусства относится керамика, однако более высокого уровня достигла керамика булгарского и золотоордынского периода.

С принятием ислама и распространением арабской письменности сложились традиции татарской каллиграфии и изготовление картин религиозного характера – шамаилей. В текстах татарских шамаилей используются коранические суры и религиозные высказывания. Шамаили занимают в интерьере каждой мусульманской семьи определённое почётное место – над дверью и на стене, указывая направление на Каабу.

Ценнейшим представителем татарского декоративно-прикладного искусства является татарский костюм. В нём, удачно дополняя друг друга, гармонично существуют вышивка и ткачество, ювелирное искусство и кожаная мозаика. Красота костюма связана с искусством кроя и целым комплексом предметов, формирующих его ансамбль. Он полностью или отдельными фрагментами используется в повседневной жизни. Важной деталью являются головные уборы, с которыми костюм приобретает не только законченный вид, но и определённое величие и красоту.



## МИЛЛИ БИЗӘГЕБЕЗ

Борын-борыннан кешеләр шартлы билгеләрдән, символлардан гади бизәкләр ясаганнар. Горизонталь, туры сызыклар белән – җир өслеген, дулкын белән суны билгеләгәннәр. Түгәрәк, квадрат, ромб фигуралары белән кояш, ай сурәтләнгән. Күптөрле бизәкләр белән чигелгән әйберләр саклагыч бөтиләр булып саналган. Нәкышләрдә чагылган гөлчәчәк матурлык һәм мәхәббәт билгесе булган. Артыш, гөлҗимеш, миләш – бәхет китерүче үсемлекләр. Бүгенге көндә дә аларның чәчәкләрен, яфракларын, ботакларын талисман итеп кулланалар. Күп таҗлы булгангадыр инде, кашкарыйлар озын гомер символы булып санала. Язның беренче чәчәкләреннән булган һәм бизәкләрдә еш кулланыла торган лалә чәчәге үзгәреш,

## НАЦИОНАЛЬНЫЙ ОРНАМЕНТ

Ещё в глубокой древности, во времена язычества, человек создавал несложные узоры из условных знаков-символов: прямой горизонтальной линией обозначалась поверхность земли, волнистой – вода, кругами, квадратами или ромбами изображали солнце и луну. Многие узоры и украшенные ими предметы считались оберегами. Так, цветок розы являлся знаком красоты и любви, а можжевельник, шиповник, рябина считались растениями счастья. По сей день принято использовать их цветы, листья, ветки в качестве талисмана. Астру (видимо, из-за большого количества лепестков) называют цветком долголетия. А тюльпан – один из первых весенних цветов и излюбленный элемент в татарском орнаменте,





яңарышны аңлата. Урталай бүленгән анар җимешен сурәтләү уңдырышлылыкны, байлыкны белдерә.

Идел буе болгарларыннан ук килә торган, башка халыкларда да популяр булган чәчәк бәйләме темасы яшәү чыганагы символы булып тора. Кошлар яисә кош каурые мотивлары, кызыл төс белән беррәттән, төрки халыкларның барысында да кояш, яктылык символы булып кабул ителгән. Ак төс сафлык, пакьлек билгесе дип санала. Күргәнебезчә, чигү җирлегенең төсе дә ниндидер мәгънә белдерә, бизәкне бербөтен итеп җыеп, тулыландырып тора.

Татар сәнгатен өйрәнүгә нигез салып, татар милли бизәкләрен классификацияләгән галим Идел буендагы беренче сәнгать фәннәре докторы Ф. Х. Вәлиев булган.

является символом возрождения. Встречаются в узорах и разрезанные плоды граната – признак богатства и плодородия.

Со времён волжских булгар дошла до нас широко распространённая тема цветочного букета, символизирующего источник жизни. Мотив птицы или птичьего пера издревле являлся у тюрков символом солнца, света, равно как и присутствие в предметах красного цвета. Белый цвет считался знаком чистоты и невинности. Цвет фона, являясь второстепенным, дополняющим элементом, придаёт целостность композиции и несёт смысловую нагрузку.

Основоположником татарского искусствоведения, классифицировавшим народный орнамент, стал первый в Поволжье доктор искусствоведения Ф. Х. Валеев.





## БИЗӘК ТӨЗЕЛЕШЕ

Бизәк – элементларның кабатлануыннан, чиратлашуыннан торган композиция. Татар бизәгендә симметрияле булмаган чәчәк бәйләме темасы бик популяр. Бу бәйләмнең нәфис сыгылган ботаклары матур чәчәкләр, яфраклар, бөреләр, бөтеркәләр белән тулыландырыла. Гадәттә, бәйләмдә төрле чәчәк мотивлары берьюлы кулланыла. Аларны алгы яктан (розетка формасында) һәм, нечкә серкәчләре белән бизәп, яннан сурәтлиләр.

Эре чәчәкләр (алар күп түгел), матур ритмик таплар буларак, сабакларның очларында, урталарында урнаша, ә ваграк чәчәк һәм яфрак элементлары калган буш урыннарны тигез итеп тулыландыра һәм бизәкне баета. Турыпочмаклы бизәкләрдә, бигрәк тә сөлге башларында, чигәсе урын үзара якын урнашкан берничә чәчәк бәйләме рәтенә бүленә.

Матур үсемлек орнаментларында гөлчәчәк, лалә, дәлия, чалма чәчәк кебек гөлләрне, аларның яфракларын танырга була.

## ПОСТРОЕНИЕ УЗОРА

Узор – это композиция, основанная на повторе чередования составляющих его элементов. В татарском узоре очень популярна тема цветочного букета, чаще асимметричного характера. Цветочный букет – это изящно изогнутая ветка, стебли которой щедро усеяны элементами цветочных головок, листьев, бутонов, завитков. Цветочные головки изображаются как с лицевой стороны (в виде розетки), так и в профиль, с тонкой вырисовкой тычинок.


Крупные цветочные мотивы ритмичными пятнами размещаются на концах стеблей, в середине. Более мелкие элементы цветов и листьев застилают всё остальное пространство. При орнаментации (края полотенец) использовался принцип разбивки пространства на сплошные ряды одинаковых, соприкасающихся друг с другом букетных композиций.

В растительных узорах встречаются цветы и листья розы, тюльпана, георгина, пиона.




Дала мотивлары.

Степные мотивы.



Болын мотивлары.

Луговые мотивы.



Бакча чәчәкләре мотивлары.

Мотивы садовых растений.



Тукранбаш мотивы.

Мотив трилистника.



Яфрак элементлары.

Элементы листьев.



## ЧИГҮ

Декоратив иҗатның бүтән төрләре белән чагыштырганда, чигү киңрәк таралган булган. Казан татар хатын-кызлары балачактан ук чигәргә өйрәнгәннәр, кияүгә чыгарга бирнә һәм туй бүләкләре әзерләгәннәр.

Чигү өчен төрле тукымалар – үзләре суккан һәм сатып алган тукымалар: ефәк, парча, бәрхет, сатин кулланылган. Ак, күк, зәңгәр, яшькелт, яшел, алтын сыман сары, ачык көрән, куе шәмәхә, ал, сирәгрәк кызыл төстәге тукымаларга яратып чиккәннәр.

Чигү өчен ефәк, катылган җепләр, мулине, гарус, йон, кайвакыт кәнитил һәм мишура кулланылган. Чигү осталары тамбур белән яратып чиккәннәр, аның асылы бизәкнең буыннарын барлыкка китергән бер үк төрле атламнар – чылбырлар ясап баруга кайтып кала. Атламнарның рәвеше буенча зур атламнар ясап чигелгән түбән тамбурны (элмә), вак атламнар ясап чигелгән югары тамбурны аералар; югары тамбур кабарып торган бау рәвешендә була һәм «күперткән элмә» дип атала. Тамбур энәсе яисә ыргак белән чиккәннәр, соңрак тамбур машиналары барлыкка килгән.

Казан татарлары сәнгатендә чәчәк бәйләмнәре рәвешендәге композицияләр киң таралган. Чәчәк бәйләмнәрен бик тә нечкә, нәфис бөгелгән сабаклар һәм эреэре чәчәкләр белән ясыйлар, алар арасына вак чәчәк мотивлары һәм бөреләре урнаштырыла. Бер үк сабакта еш кына лалә, дәлия, канәфер, гөлчәчәк, мәк, акчәчәк һ. б. гөлләрнең мотивларын күрергә була. Күп кенә очракларда бизәлә торган җирлек өстендә андый чәчәк бәйләмнәре тыгыз тасма сыман бизәк ясыйлар.

Чигелгән әйберләрдә кайвакыт кош, бал корты, күбәләк сурәтләре очрый, алар чәчәкүсемлек бизәгенә якынайтып бирелә.

## ВЫШИВКА


Вышивка, по сравнению с другими видами декоративного творчества, получила наибольшее распространение. С детства казанские татарки учились вышивать, а к замужеству готовили приданое и свадебные подарки.

Материалом для изготовления изделий служили различные ткани – самодельное и покупное полотно: шёлк, парча, бархат, сатин. Популярны были белые, голубые, синие, фисташковые, зелёные, золотистожёлтые, бежевые, фиолетовые, малиновые, реже – красные ткани.

Для вышивки использовались нити шёлковые, кручёные, мулине, гарус, шерсть, иногда канитель и мишура. Ведущей и популярной техникой вышивки татарских рукодельниц был тамбур, суть которого заключалась в выкладывании одинаковых стежков-цепочек, образующих как бы звенья узора. По характеру стежков различают тамбур низкий («элмэ»), шитый крупными стежками, и тамбур высокий – мелкими стежками, создающими впечатление рельефно нашитого шнурка («куперткэн элмэ»). Вышивки выполнялись тамбурной иглой или крючком, позже появились тамбурные машины.

Композиции в виде цветочного букета получили наибольшее распространение в искусстве вышивки казанских татар. Букеты делались с очень тонкими и изящно изогнутыми стеблями и крупными цветами, между которыми нередко разбрасывались мелкие цветочные мотивы и бутоны. Часто на одном стебле можно видеть мотивы тюльпанов, георгинов, гвоздик, роз, маков, ромашек и др. Во многих случаях на украшаемой поверхности такие букеты образовывали плотно заполненный ленточный узор.

В вышивках иногда встречаются изображения птиц, пчёл, бабочек, близкие к цветочно-растительному узору.



## АЛТЫН ҖЕП БЕЛӘН ЧИГҮ

Башка чигүләр белән чагыштырганда, алтын җеп белән чигү – иң катлаулысы. Элекке заманнарда чигү җепләрен, чыннан да, кыйммәтле металлардан җитештергәннәр. Ә бүген җепләрне «алтын», «көмеш» дип атау аларның төсләре белән генә бәйле.

Алтын җеп белән чигү татар декоратив сәнгатендә үзенчәлекле өлкәне тәшкил итә. Кул эше осталары бәрхет калфаклар һәм түбәтәйләр, данлыклы Казан сөлгеләре, китап тышлыклары, хатын-кыз читекләре, чүәкләре чиккәннәр.

Алтын җеп белән чигелгән бизәк бәрхет калфак фонында бик матур булып ялтырап тора. Чиккән вакытта, алтын җеп тукыма аша үткәрелми, икенче энә-җеп белән эләктерелеп, уң якта гына беркетелә.

Алтын җепле бизәкләрдә чәчәк-үсемлек темасы өстенлек алган. Бигрәк тә симметрияле булмаган чәчәк бәйләме композициясе киң таралган. Борынгы калфакта кош каурые сыман сыгылган ботакка нәфис итеп чәчәк мотивлары тезелгән «алтын каурый» бизәге урын алган.

Түбәтәйләрнең түбәсен дә алтын белән чиккәннәр. Бизәк түбәтәйнең яссы төбенә – шахмат тәртибендә, ә чите буйлап дулкынлы-дулкынлы чәчәк-үсемлек композициясе ясап урнаштырылган.

## ЗОЛОТОЕ ШИТЬЁ

Из всех видов вышивки золотое шитьё является самым трудоёмким и дорогостоящим. Название золотых, серебряных нитей связано лишь с их цветом. Однако в прошлом нити на самом деле изготовлялись из драгоценных металлов.

Издревле золотыми нитями вышивались бархатные калфаки и тюбетейки, знаменитые казанские полотенца, книжные обложки, женские туфли и сапожки.

Золотая нить удачно гармонирует с переливающимся фоном бархата. При вышивке нить не продёргивается сквозь ткань, а пришивается лишь по лицевой стороне при помощи второй иголки.

В золотошвейных узорах преобладает цветочно-растительная тема. Наиболее популярными являются букетные композиции асимметричной формы. На старинном калфаке довольно своеобразно смотрится узор «золотое перо», в котором цветочные мотивы как бы нанизаны на изящно изогнутое птичье перо.

Вышивки золотом покрывали и поверхность тюбетеек. Орнамент располагался по плоскому верху тюбетеек в шахматном порядке, а по их жёсткому краю – волнообразной цветочно-растительной композицией.





## ЗӘРКӘН СӘНГАТЕ

Хатын-кызлар костюмында бизәнү әйберләренә зур урын бирелгән. Зәркәнчеләрнең осталык серләре һәм эш кораллары буыннан буынга тапшырылып килгән. Зәркәнчелек белән ир-атлар да, хатын-кызлар да шөгыльләнгән. Кешеләр аерым-аерым да, кечкенә генә әртилләргә берләшеп тә эшләгәннәр. Алар ясаган әйберләр – баш хәситәсе, алка, муенса, чулпы һәм чәч тәңкәсе (тезмә), беләзек, йөзек, балдак – тәннең төрле урыннарын бизәгән.

Хатын-кыз костюмы составына кергән зәркән әйберләренең иң күзгә ташланып торганнары – яка чылбыры, хәситә (монысы иңбаш аша киелгән), изү булган.

Бизәнү әйберләренең кайберләрен (алка, йөзек, беләзек, чулпы, муенса) көн дә кигәннәр, ә кайберләрен (хәситә, изү, яка чылбыры) бәйрәм көннәрендә, кунаклар

## ЮВЕЛИРНОЕ ИСКУССТВО

Важное место в оформлении женского костюма отводилось ювелирным изделиям. Секреты мастерства и инструменты ювелиров передавались из поколения в поколение. Ювелирным ремеслом занимались как мужчины, так и женщины. Работали в одиночку и небольшими артелями. Созданные ими изделия использовались для украшения тела: головные повязки («баш хаситэсе»), серьги («алка»), ожерелья («муенса»), накосники («чулпы» и «тезмэ»), браслеты («белэзек»), перстни («йезек»), кольца («балдак»).

Из ювелирных украшений, входивших в состав женского костюма, наиболее эффектны воротниковые подвески («яка чылбыры»), перевязь («хаситэ»), которая надевалась через плечо, нагрудники («изю»).

Одни украшения (серьги, кольца, браслеты, накосники, ожерелья) были повседнев-









килгәндә, сәяхәткә чыкканда гына тагканнар.

Күпчелек очракта бизәнү әйберләрен көмештән ясаганнар һәм асылташлар, ясалма ташлар, төсле пыяла белән бизәгәннәр. Күпләп тагып йөри торган очсызрак бизәнү әйберләре өчен – түбән пробалы көмеш, кыйммәтлерәкләре өчен югары пробалысы файдаланылган. Кайвакыт көмешкә алтын йөгертү кулланылган.Татар зәркәнчеләре, бизәнү әйберләрен ясау һәм аларга бизәк төшерү өчен, төрле чаралар кулланган: көмеш каралту, уеп бизәкләү, тирән итеп һәм яссы чоку (тойма), басма, кыйммәтле металлар белән инкрустацияләү (корлау), асылташларга уеп бизәк ясау һәм уеп таш кисү, кою, яссы һәм төерле бизәк төшерү.

ными, другие (перевязи, нагрудники воротниковые подвески) носили по праздникам, при приезде гостей, в поездках.

В основном изделия делались из серебра и украшались самоцветами, искусственными камнями и цветным стеклом. Для дешёвых массовых украшений использовали низкопробное серебро, для более дорогих – высокопробное. Иногда применялось золочение серебра. Татарские ювелиры владели разнообразными приёмами изготовления и орнаментации украшений. Чернение по серебру («каралту»), гравировка («уеп бизәкләү»), глубокая и плоская чеканка («тойма»), штамповка («басма»), инкрустация драгоценными металлами («корлау»), гравировка на самоцветах и искусство огранки камней («уеп таш кисү»), литьё («кою»), плоская и бугорчатая скань.

## НӘФИС КЕРАМИКА

Балчыктан эшләнгән савыт-сабалар элек-электән киң кулланышта була. Борынгы заманнарда ук болгар осталары бик күп төрле савытлар (кувшиннар, җамаяклар, комганнар), уенчыклар ясаганнар. Яндыруның төрле фазаларын һәм югары температураны кулланып, осталар куе көрән төстән алып төтен сыман соры төскә кадәр үзенчәлекле төс гаммасын булдырганнар.

Савытларны ангоб (ак, кызыл, соры балчык), үтә күренмәле (ачык яшел төстән алып караңгы, кара төскә хәтле диярлек) лак белән каплау һәм буй-буй итеп шомарту киң таралган.

Чүлмәкчеләр иҗатының үзенчәлекле булуы төрле кошлар һәм хайваннар сурәтләре

## ХУДОЖЕСТВЕННАЯ КЕРАМИКА

Издревле изделия из глины широко использовались в быту. Ещё в давние времена булгарские керамисты производили самые разнообразные сосуды (кувшины, хумы, кумганы), игрушки. Используя различные фазы обжига и высокую температуру, мастера создавали своеобразную цветовую гамму: от тёмно-коричневого до дымчато-серого.

Широкое распространение получило покрытие сосудов ангобом (белой, красной, серой глиной), прозрачной поливой (от светло-зелёного до тёмного, почти чёрного цвета) и лощение в виде полос.

Самобытность творчества гончаров



төшерелгән савытларда да чагылыш тапкан. Түгәрәк формадагы бу сурәтләр кувшин-комганнарның тоткаларын һәм борыннарын бизәп торган.

XVI гасырның икенче яртысында юкка чыкканнан соң, керамика безнең көннәрдә хәзерге заман рәссамнары Б. Шубин, А. Абзгилдин, А. Миңнуллина, Р. Миргалимов һәм башкаларның иҗатында яңадан әйләнеп кайтты.

проявлялась в зооморфной керамике – сосудах с изображениями различных птиц и животных. Вылепленные в круглой скульптуре, они украшали ручки и сливные носики кувшинов, кумганов.

Исчезнув во второй половине XVI века, керамика возродилась в наши дни в творчестве современных художников-керамистов – Б. Шубина, А. Абзгильдина, А. Миннуллиной, Р. Миргалимова и др.



## МЕТАЛЛНЫ НӘФИС ЭШКӘРТҮ

Татар осталары борын-борыннан ук металлны нәфис эшкәртү белән шөгыльләнгәннәр. Бакыр, бронза, көмеш, кургаш һәм хәтта алтыннан бизәнү әйберләре, йорт кирәк-яраклары, ат дирбияләренең өлешләрен ясаганнар, корал бизәгәннәр.

Йорт хайваннары сыннары рәвешендә ясалган, чәчәк-үсемлек орнаментлары белән бизәлгән кечкенә генә бронза йозаклар бик кызыклы.

Соңрак осталар, нигездә, металл комганнар, су савытлары, тәлинкәләр, сыйтабаклар, тимердән коелган сандыклар эшли башлаганнар.

XV–XVI гасырларга караган, бакырдан коелган әйберләрнең уникаль үрнәге – алтын сыман сары җиздән эшләнгән шәраб кувшины. Савытка уеп язылган язу чәчәк-үсемлек орнаменты белән бердәм композиция тудырган. Кувшин суда йөзә торган кош гәүдәсенә охшатып ясалган. Савытның ике ягына бадәм чикләвеге рәвешендәге көзгеләр куелган.

Безнең көннәрдә дә кайбер татар авылларында бакырдан коеп әйбер ясаучылар очраштыра, әмма металлны нәфис эшкәртү белән бары тик профессиональ рәссамнар гына шөгыльләнә, алар үзләренең декоратив композицияләре белән җәмәгать биналарының эчке һәм тышкы якларын бизиләр.

## ХУДОЖЕСТВЕННАЯ ОБРАБОТКА МЕТАЛЛА

С древнейших времён татарские мастера занимались художественной обработкой металла. Из меди, бронзы, серебра, свинца и даже золота они делали украшения, предметы домашней утвари, составные части конского снаряжения, украшали оружие.

Интересны небольшие бронзовые замочки в форме фигурок домашних животных, украшенные простым цветочно-растительным узором.

Позднее мастера производили в основном металлические кумганы, сосуды для жидкостей, блюда, подносы, кованые сундучки.

Уникальным образцом медно-чеканных изделий XV–XVI веков является винный кувшин из золотисто-жёлтой латуни. Выгравированная на сосуде надпись создаёт единую композицию с цветочно-растительным орнаментом. Форма кувшина стилизована под туловище водоплавающей птицы. С двух сторон в стенки сосуда вставлены оловянные зеркала миндалевидной формы.

И в наши дни в некоторых татарских деревнях можно встретить мастеров, создающих медно-чеканные изделия, однако художественной обработкой металла занимаются лишь профессиональные художники, которые своими декоративными композициями украшают интерьеры и экстерьеры общественных зданий.







## БИЗӘКЛӘП ТУКУ

Бизәкләп туку өй һөнәрчелеге һәм вак мануфактуралар рәвешендә яшәп килгән. Татар кызлары һәм хатыннары борын-борыннан, сәгатьләр буе туку станы артында утырып, үзләренә – бирнә, туган-тумачаларына һәм кияүләренә, Сабантуйга – бүләкләр, йорт өчен чаршаулар, кашагалар, сөлгеләр әзерләгәннәр.

Оста куллар бизәкләп туку техникасының барлык төрләрен белгәннәр. Болар – чүпләмле туку, төсле чүпләм, кыялап сугу һәм аеруча традицион булган асалап сугу. Кызыл яки алсу төстәге борынгы сөлгеләргә төшерелгән эре-эре, катлы-катлы геометрик бизәкләр, нигездә, буй-буй итеп сөлге читләренә урнаштырылган: төп буй киң булып, як-якта таррак бизәкләр ясалган. Өске

## УЗОРНОЕ ТКАЧЕСТВО

Узорное ткачество существовало в виде домашнего ремесла и мелких мануфактур. Издавна татарские девушки и женщины проводили долгие часы за ткацким станком, готовя себе приданое, подарки родственникам и жениху, призы для Сабантуя, «мягкую утварь» для дома (занавески, подзоры, полотенца).

Мастерицы владели всеми видами техники узорного ткачества: браного («чуплэмле туку»), выборного («тосле чуплэм»), многоремизного («кыялап сугу») и традиционного закладного ткачества («асалап сугу»). Крупные многоступенчатые геометрические фигуры на приглушённо-красном или светло-розовом фоне старинных закладных полотенец заполняют бордюры, расположенные



һәм аскы буйдагы бизәкләр, гадәттә, берберсен кабатлап килгән.

Тукыма тукыганда, барлык төсләрнең дә диярлек (кара төстән тыш) төрле төсмерләре кулланылган. Тукыманың җирлеге, гадәттә, кызыл төстә булган.

XIX гасырның икенче яртысыннан алып бизәкләр ваграк, җиңелрәк, челтәрлерәк була башлый. XIX гасырдагы кайбер сөлгеләрдә бизәкләр тар буйчалардан гына тора.

Күп төсле чүпләмле бизәкләр, асалап сугу кебек үк, ачык җете төсләре, төсләрнең байлыгы белән аерылып тора. Аларда кара төстән тыш барлык төп төсләр дә кулланылган. Бизәкләр күбрәк кызыл, ал җирлеккә төшерелгән. Кызыл төс тукымага тантана, бәйрәм төсмере биреп торган.

полосами. Узоры верхней и нижней полосы обычно повторяют друг друга.

Колористические решения закладов исходили из контрастного сочетания различных оттенков почти всех цветов, кроме чёрного. Фон ткани обычно был красного цвета.

Со второй половины XIX века фигуры закладов становятся более дробными, лёгкими, ажурными. В некоторых полотенцах XIX века узоры состояли только из узких полосок.

В геометрических узорах закладных и выборных тканей использовались почти все основные цвета. Для фона использовались оттенки красного. Красный цвет придавал тканям праздничный вид.





## КҮН ЭШКӘРТҮ СӘНГАТЕ

Безнең якларда төрле йомшак күн – сәхтиян аяк киемнәре тегү сәнгате гаять киң таралган. Болгар илендә күн, тире эшкәртү алымнары борын-борыннан булган. Югары сыйфатлы сәхтиян, юфтьтән эшләнгән күн читекләрне, чүәкләрне җирле халык кына түгел, бәлки башка төбәк халыклары да яратып кигән.

Бизәкләп эшләнгән аяк киеме җитештерү техникасы шактый катлаулы булган. Осталар берьюлы берничә пар аяк киеме килеп чыгардай калдыксыз эшләү юлын тапканнар. Аяк киеме кисүче төрле төскә буялган юеш күнне бер өем итеп куйган һәм бизәкне берьюлы берничә читек өчен кискән. Аннан соң, күн катламнар арасында кайбер элементларны алыштыргач, төрле төстәге бизәкләр барлыкка килгән. Бизәкнең контуры булып торган махсус декоратив җөй ярдәмендә әлеге элементлар мозаика техникасы белән тезелгән һәм беркетелеп куелган.

Элек-электән аяк киеменең үзенчәлекле бизәкләренә кешене саклау, магия мәгънәсе

## ИСКУССТВО КОЖАНОЙ МОЗАИКИ

В наших краях широкое распространение получило изготовление мягкой кожаной обуви. Ещё волжские булгары славились мастерством выделывания кожи. Сшитые из мягкого сафьяна или юфти узорные сапожки, туфли пользовались большим спросом не только среди местного населения, но и за пределами края.

Техника изготовления обуви, получившей название «азиатской», была довольно сложной. Мастера выработали свой способ безотходного производства, при котором одновременно получалось несколько пар сапог. Закройщик складывал стопкой несколько пар разных цветов влажной кожи и вырезал орнамент всех сапог. Затем, меняя между пластами некоторые элементы узора, создавалась многоцветная композиция. Составленные в технике мозаики мотивы сшивались специальным декоративным швом, служившим контуром узора.

Издавна своеобразному орнаменту обуви придавалось охранно-магическое значение. В основе узоров – растительные и





бирелгән. Бизәкләр нигезендә – үсемлек һәм җәнлек мотивлары. Алар арасында болыт сыман, лотос сыман сурәтләр, пальметта, лалә чәчәге киң таралган. Читек элементлары чигү бизәкләреннән мөгез, песи башы, йөрәк формасындагы сурәтләре булу белән аерылып тора. Читекнең өске өлешендәге дулкын мотивы суны гәүдәләндерә.

Төсле фон ярдәмендә шактый эре һәм йомык формалы элементлар бербөтен һәм үзенчәлекле бизәк композициясен тәшкил итә.

Бу матур традиция – сәнгатебезнең күн эшкәртү төре – бүген дә гамәлдә. Күн мозаикасы стилендә җиңел аяк киемнәре, башмаклар тегәргә мөмкин. Башмакның аскы өлешен калын олтырактан ясарга яисә каты киез итек балтырыннан кисәргә була. Өске өлеш бирелгән өлге буенча бәрхеттән, велюр яисә күннән киселә.

Бизәкне төрле ысуллар һәм материаллар белән эшлиләр. Төсле тукыма һәм күн кисәкләреннән, мозаика сәнгатенә килештереп, аппликация ясала. Бизәкнең контуры тегү машинасы яисә кул белән тегелә. Аны декоратив баулар, жгутлар, сәйлән, мулине җебе белән матурларга мөмкин. Башмакның өске һәм аскы өлешләре тоташкан урынны тар тасма белән эшкәртеп чыгарга тәкъдим ителә.

зооморфные мотивы. Среди популярных – облакообразные, лотосовидные, тюльпанообразные, пальметтообразные узоры, также всевозможные роговидные, сердцевидные элементы. Верх ичигов украшался мотивом набегающей волны, символизирующим воду.

На основе цветного фона довольно массивные и замкнутые по форме элементы собираются в единую гармоничную композицию.

Техника художественной обработки кожи и по сей день применяется в практике отдельных мастеров. В стиле кожаной мозаики можно изготовить домашнюю обувь, тапочки. Для подошвы можно взять готовую толстую стельку или выкроить её из плотного войлока, кожи. По предложенному лекалу из бархата, велюра, кожи или махровой ткани выкраивается верхняя часть тапочек.

Узор может быть самым разнообразным. Используя ткани разных оттенков, делается аппликация под мозаичные узоры или вышивается растительный орнамент. Контуры обрабатываются на машине или вручную. Одновременно можно использовать декоративные шнуры, жгуты, бисер, мулине. Места соединений верха и подошвы обрабатываются косой тесьмой.

## КАЗАН СӨЛГЕСЕ

Әүвәлге заманда безнең якларда рәсем сәнгатен чигү алыштырган. Кул эше осталары матур чигешләрдә үзләренең дөньяга мөнәсәбәтен күрсәткәннәр. Шуңа күрә сөлгеләр, сөртенер өчен генә түгел, ә сәнгать әсәрләре дәрәҗәсенә күтәрелеп, йорт стеналарын, тәрәзә яңакларын бизәүдә кулланылган.

Сөлгеләр шулай ук хәзерге заманда да бәйрәм-йолаларның төп атрибуты булып тора. Зур осталык белән чигелгән сөлгеләр тырышлык, чисталык, сафлык билгесе булып санала.

Дала, кыр һәм бакча үсемлекләренең сурәтләре чигүләрдә искиткеч нәфислек белән бирелә. Бизәкнең композициясе әйбернең кулланылышы, формасы белән бәйле.

Татар сөлгеләренең ике башында уртага таба юнәлгән бертөрле бизәк композициясе урнаша. Гадәттә, орнамент бер-берсенә якын урнашкан өч-дүрт чәчәк бәйләменнән тора. Бәйләмнең нәфис сыгылган ботаклары матур чәчәкләр, яфраклар, бөреләр белән мул итеп бизәлә. Чәчәк бәйләмнәре астан тар гына дулкынлы бизәк белән тулыландырыла.

## КАЗАНСКОЕ ПОЛОТЕНЦЕ

Отсутствие станковой живописи в прошлом компенсировалось искусством вышивки. В вышивках мастера выражали своё мироощущение. Украшенные выразительной вышивкой и поднявшиеся до уровня произведения искусства полотенца широко использовались не только для бытовых целей, но и в оформлении жилищ.

Также они являются главным атрибутом праздников и обрядов, олицетворяют трудолюбие, чистоту, невинность.

В узорах с удивительной нежностью представлены самые разнообразные мотивы луговых и садовых растений. Композиция вышивки во многом зависит от назначения изделия и его формы.

На татарских полотенцах единый композиционный узор украшает оба его конца. Чаще всего орнамент состоит из трёх-четырёх почти соприкасающихся друг с другом цветочных букетов. Букет представляет собой изящно изогнутый стебель, обильно усеянный элементами бутонов, листьев. По низу букетные композиции обрамляются узким волнистым узором.



## ШӘМАИЛ

Шәмаил һәрбер мөселман гаиләсендә дә бар диярлек. Ул безнең дини культурабыз белән бәйләнгән сынлы сәнгать әсәре. Шәмаилләрдә, матур орнамент, натюрморт яисә архитектура пейзажлары белән бизәлеп, Коръән сүрәләре бирелә.

Бакый Уманче беренче шәмаилен 1970 елда иҗат иткән. Шәмаилләрне алтын һәм көмеш җепләр, шулай ук энҗе, сәйлән белән чигәргә, гарәп язуы һәм мәчет рәсеме белән тулыландырырга мөмкин.

Россия һәм Татарстан рәссамнар берлеге әгъзасы Нәҗип Нәккаш гарәп каллиграфиясе белән шөгыльләнүче һәм борынгы традицияләребезне лаеклы дәвам итүче буларак танылды.

## ШАМАИЛЬ

Шамаиль имеется в каждой мусульманской семье. Это живописно-графическое произведение, связанное с духовной культурой. Тексты сур из Корана, написанные изысканной арабской вязью, дополняются красивой орнаментальной композицией, натюрмортом или архитектурными пейзажами.


Баки Урманче сделал свой первый шамаиль в 1970 году. Шамаили можно вышивать золотыми, серебряными нитями или бисером, дополняя орнаментальной вязью и изображением мечети.

Достойным продолжателем древних традиций и ведущим художником в области арабской каллиграфии является член Союза художников России и Татарстана Назип Наккаш.



Шәмаил. Пыяла, фольга, буяулар. Нәҗип Нәккаш эше.
Шамаиль. Стекло, фольга, краски. Работа Назипа Наккаша.




Шәмаил. Кәгазь, буяулар. Рушан Шәмсетдинов эше.
Шамаиль. Бумага, краски. Работа Рушана Шамсутдинова.

## ТАТАР КОСТЮМЫ

Традицион татар костюмы үзенең матурлыгы һәм зәвыклылыгы белән сәнгатебезнең кабатланмас үрнәге булып тора. Бербөтен һәм искиткеч гармонияле татар костюмында, бер-берсен тулыландырып һәм баетып, кием кисү, туку, күптөрле чигү, зәркәнчелек һәм күн мозаикасы кебек сәнгать төрләре чагыла.

Күп халыклардагы кебек, татар костюмының нигезе бер генә төсле иркен туника сыман күлмәктән тора. Алар күбрәк бала итәкле итеп, бөрмәләп, чуклар белән бизәлеп тегелгән. Гадәттә, бер халыкның да милли күлмәкләре аерым гына киелмәгән. Татар хатын-кызлары күлмәк өстеннән авыр ефәк яки бәрхет тукымадан тегелгән һәм декоратив тасма белән бизәлгән камзул, җылы бишмәт, кәзәки киеп йөргәннәр.

Изү яки хәситә кебек салына торган бизәнү элементлары костюмга бәйрәм төсмере өсти һәм аның затлылыгын арттыра. Изү – күлмәкнең түшен каплап торган, бертөсле тукымадан тегелгән бизәк. Аның түгәрәкләнеп торган ягы буйлап декоратив тасма тегелә һәм төрле тәңкәләр, брошкалар беркетелә. Шундый ук матур брошкалар белән бизәлгән оригиналь хәситәләр күлмәкне баетып тора.

Костюмның бер өлеше булып, бигрәк тә авыл җирендә, күкрәкчәле алъяпкычлар саналган. Алар эш һәм бәйрәм өчен тегелгән. Алъяпкычны чигүле җиңсә белән берләштереп кию костюмга үзенчәлекле төсмер бирә.

Халык костюмында баш киемнәренә әһәмиятле урын бирелә. Аларга формалары, күләмнәре белән төрле-төрле булган чигүле калфаклар керә. Кияүдәге хатыннар, башлары белән беррәттән муен, арка, иңбашларын капларга тиеш булганга күрә, баш киеме өстеннән «тастар», «өрпәк» кебек баш япмалары, шәлләр, яулыклар киеп йөргәннәр.

Үзендә табигать шартларын, дин һәм традицияләрне, күрше халыклар белән мөнәсәбәтләрне чагылдырып, милли костюм да җәмгыять белән бергә үсеш-үзгәрешләр кичергән. Бөенте һәм җиң төбе хисабына зур һәм күп катлы күлмәкләр акрынлап җиңеләя һәм тарая бара, авыр бизәнү әйберләре дә кулланылыштан чыга.

Ирләр киеме зур үзгәрешләр кичермәгән.

## ТАТАРСКИЙ КОСТЮМ

Традиционный костюм татарки во всей своей красе, величии и женственности является ценнейшим памятником народного искусства. В едином и вполне гармоничном комплексе костюма, взаимообогащая и дополняя друг друга, нашли своё отражение искусство кроя, ткачества, разнообразная вышивка, ювелирные изделия и кожаная мозаика.

Как и у многих других народов, основу костюма составляет однотонная просторная рубаха туникообразного покроя. Часто платья шились с присборенным подолом и украшались широкими воланами, оборками или бахромой. Как правило, рубахи отдельно не носились. Поверх платья обязательно носили камзол, сшитый из тяжёлых шёлковых или бархатных тканей и украшенный тесёмочной отделкой, а также бешметы, казакины.

Съёмные украшения придавали костюму праздничный и роскошный вид. Популярным являлся нарядный нагрудник, прикрывавший сверху вырез платья. Вдоль закруглённой стороны нагрудника пришивалась декоративная тесьма, куда крепились монеты, броши. Костюм дополняла и украшенная брошами перевязь.

Незаменимым элементом, особенно сельской, одежды являются передники с нагрудниками, которые делились на праздничные и будничные. Фартуки носились в сочетании с узорными нарукавниками.

Особое значение в народной одежде уделялось головным уборам. Это разнообразные по форме и размеру калфаки. Замужние женщины, кроме головы, должны были прикрывать шею, плечи, спину. Поэтому активно использовались шали, покрывала, платки, под которыми надевали нижние уборы – волосники, состоявшие из шапочки и накосника.

Костюм развивался и видоизменялся вместе с обществом, отражая жизненные устои и природно-климатические условия, традиции и религию, уровень развития и соседские отношения. За счёт пройм и вытачек татарский костюм постепенно из громоздкой и многослойной одежды превратился в более лёгкую и облегающую, без тяжеловесных перевязей.

Исторические изменения мужской одежды коснулись меньше. Мало чем отличают-









Күлмәк өстеннән киелә торган камзул, бишмәт, җилән хатын-кызларныкыннан аз аерылып тора. Түбәтәйләр дә күп гасырлар буе формаларын югалтмый.

Хәзерге заман рәссам-модельерлары үз иҗатларында халкыбыз традицияләренә әйләнеп кайталар. Милли кием теккәндә, халкыбызның рухын, үзенчәлеген, туган җиребезнең матурлыгын күрсәтергә омтылалар.

ся мужские камзолы, бешметы, джиляны от женских. Неизменными остаются головные уборы – тюбетейки.

Художники, модельеры и в наши дни обращаются к народным традициям. Создавая современную одежду в народном стиле, дизайнеры стремятся воплотить в них национальный дух, своеобразие и красоту родного края.



## КАЛФАК

Калфак – гамәли сәнгатебезнең татар хатын-кызларын гүзәллек алиһәсе дәрәҗәсенә күтәрә торган үзенчәлекле элементы.

Вакытлар узган саен калфакларның формасы, бизәлеше үзгәрә тора. Элек ак трикотаж калфаклар популяр булган. Аларны зур, башка киелә торган итеп теккәннәр яки бәйләгәннәр. XVIII гасыр калфаклары бизәлешендә синель ябыштыру һәм тырнак алмалау техникасы өстенлек алып торган.

Соңрак чуклары аркага кадәр төшеп торган «капчык» калфаклар популяр булган. Алар, бәрхеттән тегелеп, алтын ука белән чигелгәннәр.

XIX гасырдан алып бүгенге көнгә кадәр калфаклар, ука яки кәнитил белән беррәттән, ак, сирәк очракта төсле сәйлән кулланып чигелә. XIX гасыр урталарында кечерәк «капчыклы» хәтфә калфаклар модага керә. Еш кына андый калфакларны яуры, орнаментация калфаков, впрочем, как и весь национальный костюм, постоянно изменялись.

Раньше были популярны белые мягкие трикотажные или вязаные калфачки с вышивкой, которые надевались на всю голову. С XVIII века в орнаментации калфаков широко использовались аппликация синелью и ушковая техника.

К середине XIX века калфаки становятся значительно короче, изящнее, исчезают тяжёлые кисти и бахрома. Большую декоративную функцию берёт на себя твёрдый прямоугольный околышек. Часто такие калфачки носились под платком или шалью.

Постепенно золотошвейные калфачки с твёрдым околышком приобретают уменьшённую форму. Калфак уже не надевается на голову, а является лишь своеобразным украшением. С XIX века в орнаментации калфаков широкое применение получает белый, реже – цветной бисер.







лык яки ефәк шәл астыннан киеп йөргәннәр.

Бүгенге көндә кечкенә калфакларны сәхнәләрдә генә кияләр, ә көндәлек куллынылышта түбәтәй формасындагы «такыя» калфаклар йөри.

## КАЛФАК

На протяжении веков форма, разме-

Маленькие калфачки в наши дни используются лишь в сценической деятельности, но зато весьма популярны калфаки в форме тюбетейки – «такия».

## КАЛФАК ТЕГҮ ҺӘМ ЧИГҮ

Кирәкле әйберләр: хәтфә (бәрхет), эчлек өчен сатин яки ситсы, калфак киңлегендә

һәм 6 см биеклектә корсаж лента (каты тукыма), бизәк төшерү өчен аксыл тукыма кисәге, вак энҗе, аксыл яки ак төстәге сәйләннәр, пыяла сәйләннәр. Сәйләндәге тишек аша җиңел үтәрлек ике энә, аксыл җеп алыгыз.

Киергә түгәрәк һәм дүртпочмаклы булырга мөмкин.

Бизәкне ак тукымага төшерү өчен, копировка кәгазе яисә трафарет кирәк.

Эш барышы:

1. Үзегез теләгән фасонлы, размерлы өлге әзерләү.
2. Бизәк ясау яки сайлап күчерү.
3. Калфакны һәм аның эчлеген кисү.
4. Калфакның алгы өлешен чигү.
5. Алгы һәм арткы өлешләрен тоташтырып тегү.
6. Калфакның эчлеген тегү.

## ИЗГОТОВЛЕНИЕ КАЛФАКА


Необходимые материалы: бархат, ситец или сатин для подкладки, корсажная лента или жёсткая ткань высотой 6 см, светлая ткань для нанесения узора, мелкий жемчуг, белый или светлых тонов бисер, стеклярусы, две иголки, которые свободно проходят в отверстие бисера, а также белые нитки.


Пяльцы могут быть как круглые, так и квадратные.


Для нанесения узора на белую ткань необходима копировальная бумага или можно использовать трафарет.


Ход работы:


1. Изготовление из бумаги выкройки калфака нужного фасона и размера.
2. Нанесение на него узора.
3. Выкраивание калфака и его подкладки.
4. Вышивание калфака.
5. Сшивание его деталей.
6. Шитьё подкладки.











## Каты кырпулы калфак

Хәтфә калфакларны, декоратив бизәү алымнарына карап, энҗеле, тәңкәле калфак дип йөрткәннәр.


Буе якынча 22 см, иңе 16–18 см лы ике катлы хәтфә әзерләгез. Плюш калфаклар да матур күренә. Төсен киемегезгә, камзулыгызга туры китереп сайлагыз. Калфакның маңгай өлеше якынча 6 см биеклектә, ә өске өлешенең биеклеге 16–18 см була. Маңгай өлешен өскә бөкләр өчен, 1–1,5 см материал калдырыгыз.

Калфакны аерым өлешләрдән дә тегәргә

## Калфак с жёстким фризом

Для небольшого калфака потребуется сложенный вдвое отрез бархата (примерно 22 см в длину и 16–18 см в ширину), сочетающийся по цвету с вашим костюмом (камзолом). Можно также использовать вместо бархата плюш.

Примерная высота надлобного прямоугольного фриза – 6 см, а высота верхней части калфака – 16–18 см. Между нижней и верхней частями необходимо оставить запас в 1–1,5 см для сгиба, который создаст вид отворота.



мөмкин (1 рәс.). Эшнең башында өлге әзерләргә кирәк. Башта китапта бирелгән рәсемнәрне копировка кәгазе ярдәмендә ак төстәге тукымага төшереп алыгыз һәм барлыкка килгән өлгене ике катлы хәтфәгә куеп, тегү җөе өчен урын калдырып кисегез. Эчлекне дә шулай ук кисегез һәм калфакның арткы өлеше белән бергә читкә куеп торыгыз.


Чигәр алдыннан, калфакның алгы өлешенә бизәк төшерергә кирәк. Бизәк төшерелгән ак тукыманы бәрхетнең эчке ягына беркетәбез. Бизәкне, ак җеп кулланып, өзек-өзек атламнар белән тегеп чыгарга кирәк. Бизәкне трафарет белән дә төшерергә мөмкин.

Калфак можно сшить и из отдельных деталей (рис. 1).


Сначала необходимо сделать выкройку из бумаги и нанести на неё один из орнаментов, представленных в книге. Затем положить её на сложенный вдвое бархат и раскроить переднюю и заднюю части калфака. Таким же образом из ситца выкраивается подкладка. Не забудьте оставить припуски на швы. Переднюю деталь подготовьте для вышивания.


Узор на бархатной основе с изнанки воспроизводится при помощи стежков контрастными нитками. Можно нанести узор и трафаретом.

1 рәс.
Рис. 1









## Калфак өлешләрен тоташтыру

Чигүле маңгай өлешенең өстен 1–1,5 см киңлектә эчкә бөкләп, калфакның сул ягыннан тегеп чыгыгыз. Сул якта 0,5–0,7 см лы җөй барлыкка килер. Калфакның икенче, чигүсез өлешендә дә шундый җөйләр ясагыз. Соңыннан калфакның ике өлешен дә, уң яклары белән бергә тоташтырып, бер кырыеннан тегеп чыгыгыз. Хәзер исә 6 см киңлектәге калын киндер яки корсаж тасманы калфакның сул ягында калдырылган 0,5 см лы җөйгә беркетегез. Ул калфакның маңгай өлеше йомарланмасын, формасы саклансын өчен беркетелә. Шуннан соң калфакның икенче ягы тегелә. Калфак бармаксыз бияләйне хәтерләтер. Аның эчлеген дә тегеп куегыз (2 рәс.).

Башка кими торган кечерәк размерлы калфакка, күренеп тормаслык итеп, резин тасма тегәргә кирәк.

Калфаклар арасында зур, чуклары җилкәгә төшеп торган, капчык сыманнары да бик популяр (3 рәс.).

Өлкән яшьтәге хатын-кызлар ак шәл яисә ефәк яулык астыннан кәләпүш формасындагы «такыя» калфаклар кияләр. Аларның маңгай турысын, кайвакытларда түбәсен дә чигәләр. Бу калфакның чите – түбәтәйнеке кебек, түбәсе түгәрәк яисә овал формасында киселә.

## Сшивание деталей калфака


Над нижним прямоугольным фризом сделайте сгиб в 1–1,5 см и пришейте его с изнанки. При этом образуется выступ в 0,5–0,7 см. То же самое проделайте и на другой части калфака. Затем сшейте, сложив вместе лицевые стороны, обе части по одной стороне. Для создания жёсткости надлобной части к выступу над фризом (0,5 см) по всей длине пришейте корсажную ленту шириной 6 см (рис. 2). После чего дошивается остальная часть калфака, который приобретает форму беспалой варежки. Сшейте подклад и аккуратно пришейте его внутрь калфака.

Для малого калфака, который не надевается на голову, по бокам необходимо пришить незаметную резинку.


Очень красиво смотрятся большие мешкообразные калфаки, обрамлённые бахромой. Предлагаем уменьшённую выкройку такого калфака (рис. 3).

В современной повседневной жизни наиболее популярны, особенно среди женщин преклонного возраста, калфаки «такия». У них вышивается жёсткая надлобная часть, а иногда и верх. Боковая часть выкраивается как край тюбетейки. Верх круглый или чуть-чуть овальный с прямым передом. Для жёсткости пришивается корсажная лента.


2 рәс.
Рис. 2




3 рәс.
Рис. 3








Такыя калфак өлгесе.
Лекало калфака «такия».



## ТҮБӘТӘЙ

Түбәтәй ислам динен тотучы төрки телле халыкларда ирләрнең төп баш киеме булып санала. Татарларда түбәтәйләрнең ике төре билгеле: ярымшар формасындагы «такыя» һәм кисек конус формасындагы кәләпүш.

Аерым чөй сыман өлешләрдән тегелгән «такыя» борынгырак төргә керә. Ул, галимнәр фикеренчә, борынгы сугышчыларның шлем астыннан киеп йөри торган баш киеменнән үзгәргән булса кирәк.

XIX гасыр уртасыннан алып бүгенге көнгә кадәр яссы формалы кәләпүш-түбәтәйләр күбрәк кулланыла. Ике төр түбәтәй бар: чигүсез һәм ефәк җепләр, алтын һәм көмеш кәнитил, энҗе-сәйлән белән чигелгәннәре. Зәвык белән чигелгән парча түбәтәйләр бигрәк тә матур күренәләр.

XIX гасыр башында чигелгән түбәтәйләрнең өслекләре дулкын сыман чәчәкле композиция һәм геометрик мотивлар белән бизәлгән булган.

Вакыт узу белән, түбәтәй бизәкләре дә үзгәрә. XIX гасырның икенче яртысында түбәтәйләрнең түбәсендәге үзәк чәчәк әйләнәсендә түгәрәк буйлап урнашкан композиция берничә зур чәчәк бәйләмнәре булган бизәкләр белән алыштырыла.

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башларына инде зур чәчәк бәйләмнәрен кечкенә, гади,

## ТЮБЕТЕЙКА

Существовали два основных вида татарских тюбетеек – «такия» полусферической формы и каляпуш в форме усечённого конуса.

«Такия», сшитая из отдельных клиньев, относится к наиболее старинным видам. Как считают исследователи, происхождением своим она обязана подшлемнику древнего воина.

Каляпуш с твёрдым краем и плоским верхом появился в середине XIX века и популярен по сей день. Существуют однотонные и расшитые тюбетейки. Каляпуши из бархата расшивались шёлковой нитью, золотой или серебряной канителью, позже – жемчугом и бисером. Наиболее нарядны со вкусом расшитые парчовые тюбетейки.

Более старинные тюбетейки первой половины XIX века отличаются тем, что крупные волнообразные цветочно-растительные композиции и геометрические мотивы покрывали всю украшаемую поверхность головного убора.

Со временем узор тюбетеек изменился. Ко второй половине XIX века на верхней части тюбетейки узор по окружности с розеткой посередине был заменён орнаментом, составленным из нескольких крупных букетиков, расположенных по кругу.

аерым-аерым урнашкан букетлар алыштыра башлый. Моның белән түбәтәйләрнең матурлыгы, кыйммәте түбәнәя. Шушындый гади ысул белән чигелгән түбәтәйләр безнең заманда да киң кулланыла.

К концу XIX – началу XX века крупные цветочные букеты заменяются мелкими, менее выразительными букетиками. Таким образом, производство тюбетеек становится более дешёвым и доступным для широкого круга населения.



## ТҮБӘТӘЙ ТЕГҮ ҺӘМ ЧИГҮ

Кирәкле әйберләр: кара, яшел һәм башка төстәге хәтфә, ефәк яисә парча, эчлегенә ситсы яки сатин, 15 м чамасы озынлыкта сүс җебе (булмаганда, киндер капчыкны сүтеп, кер сабыны белән ышкып, бөтереп, җеп әзерләргә мөмкин), ак һәм хәтфә төсендәге кәтүк җебе, сәйлән өчен нәзек, гадәти һәм зур күзле юан энәләр, кәкре башлы камыт энәсе, сәйлән яки ука, кәнитил, киерге, копировка кәгазе.

Эш барышы:

1. Үзегезгә кирәкле өлге ясау.
2. Хәтфәдән түбәтәй өлешләрен кисү.
3. Түбәтәйнең эчлеген кисү.
4. Түбәтәйнең читен һәм түбәсен чигү.
5. Түбәтәйнең өлешләрен тегү һәм сыру.
6. Түбәтәйне тегеп бетерү.

## ИЗГОТОВЛЕНИЕ ТЮБЕТЕЙКИ

Необходимые материалы: бархат чёрного, зелёного или другого цвета (либо шёлк, парча), хлопчатобумажная основа для подклада, около 15 м шпагата (можно использовать кручёные и смазанные воском нити от распущенных льняных мешков), белые и в тон цвета тюбетейки катушечные нитки, тонкая, средняя и большая со слегка согнутым концом и большим ушком иглы, бисер или золотая, серебряная нити, канитель, пяльца, копировальная бумага.

Ход работы:

1. Изготовление выкройки.
2. Выкраивание из бархата частей тюбетейки.
3. Раскрой подкладки.
4. Вышивание верха и края тюбетейки.
5. Простёгивание частей тюбетейки.
6. Сшивание частей тюбетейки.

### Өлге ясау

Белгәнебезчә, түбәтәй ике өлештән – яссы түбәдән һәм каты читтән тора. Түбәтәй чите кыеклап киселә. Аның озынлыгы баш үлчәменә җөй өчен 2 см кушудан килеп чыга.


Түбәтәйнең биеклеге 8–9 см, һәм аңа тагын 1,5–2 см өстәмә кушкач, ул 10–11 см була. Димәк, 58 нче үлчәмле түбәтәй читенең озынлыгы 60 см, киңлеге 10–11 см була. Әзер түбәтәй исә 8–9 см дан да биегрәк булмаска тиеш.

### Изготовление выкройки


Тюбетейка состоит из двух частей: из плоского круглого верха и жёсткого края. Боковая часть выкраивается по косой. Её длина равна окружности головы плюс 2 см на шов.


Высота тюбетейки равна 8–9 см, плюс 1,5–2 см на шов, получается 10–11 см. Значит, для 58-го размера делаем выкройку тюбетейки длиной края 60 см и шириной 10–11 см. Высота головного убора не должна превышать 8–9 см.

### Түбәтәйнең өлешләрен кисү



### Раскрой тюбетейки






Тегү өчен запас белән әзерләнгән өлгене хәтфә өстендә кыекка куеп, түбәтәйнең өлешләрен кисегез. Берьюлы берничә түбәтәй кисәргә була (4 рәс.). Аның эчлеге дә шулай ук кыекка киселә, ләкин ул тышлыкка караганда 1 см га озынрак һәм киңрәк булырга тиеш.


Димәк, 58 нче үлчәмле түбәтәйнең эчлеге 61 см озынлыкта, 10–12 см киңлектә була. Түбәсе әйләнә озынлыгына, ягъни баш үлчәменә туры килгән, диаметры 19 см (радиусы 9,5 см) булган түгәрәк рәвешендә була. Каты кәгазьдән өлге әзерләп, түбәтәйнең түбәсен һәм эчлеген кисегез (5 рәс.).

С припусками на шов подготовленную выкройку края кладут на бархат так, чтобы долевая нить ткани располагалась по косой линии. Из прямоугольного отреза кроят сразу несколько тюбетеек (рис. 4). Подкладка края тюбетейки выкраивается также по косой. Она должна быть на 1 см длиннее и шире бархатной части.


Для 58-го размера понадобится подкладка длиной 61 см, шириной 10–12 см. Диаметр верха тюбетейки – 19 см (радиус – 9,5 см). Размеры даны с припусками на швы. Сделав из жёсткой бумаги лекало, скроите верх и его подклад (рис. 5).





4 рәс.
Рис. 4




5 рәс.
Рис. 5





# Түбәтәй чигү

Чигелмәгән түбәтәйләр дә халык арасында киң кулланылышта йөри. Шулай да алтын яки, көмеш кәнитил, энҗе яки сәйлән белән бизәлгәннәре элек-электән үк киң кулланылган. Ефәк белән парчадан тегелгән түбәтәйләр дә булган. Кайберләренең түбә уртасына чук такканнар.

Түбәтәйне, өлешләрне кискәч, сырырга керешкәнче чигәләр. Бизәкләр өчен төрле төстәге сәйләннәр кулланырга мөмкин.

Бизәкне артык чуар итәргә тырышмагыз. Алтын кәнитилгә охшатып, сары төстәге бизәк ясасагыз да матур булыр.

Иң элек түбәтәй өлешләрен зур киергегә киертелгән тукымага беркетәләр, аннан соң бизәк чигәләр.

Чигүнең матурлыгы үз зәвыгыгыздан, төсләр сайлый белүегездән, эшне дөрес, пөхтә итеп эшли алуыгыздан тора.

# Вышивка тюбетейки

Большой популярностью пользуются и тюбетейки без вышивки. Однако многие предпочитают уборы, вышитые золотой, серебряной канителью, жемчугом или бисером. В особых случаях тюбетейки шились из шёлка и парчи. К макушке некоторых тюбетеек пришивали бахрому.

Процесс вышивания частей тюбетейки происходит до простёгивания, сразу же после раскроя. Бисер можно использовать как одного цвета (например, жёлтого, под золотое шитьё), так и нескольких сочетающихся по тону цветов.

Вначале детали тюбетейки приклеиваются на запяленную ткань, затем на неё наносится узор.

Красота изделия напрямую зависит от умелой организации работы, аккуратности, художественного вкуса мастерицы.

# Тегү һәм сыру тәртибе

Түбәтәй тегүнең асылы вак атламнар белән җөй ясап, кулдан тегеп чыгудан гыйбарәт. Түбәтәй формасын сакласын өчен, җөйләр арасына сүс җепләре үткәрелә.

Тегүне түбәтәй читенең аскы өлешеннән башлагыз. Тасма формасындагы бәрхет һәм ситсы эчлек тукымаларның уң якларын бергә салып, башта аскы өлешен сул яктан тегегез. Аннан соң тукымаларны уң якка әйләндереп, эчлек күренеп тормаслык итеп, бәрхетне 1–2 мм эчлек ягына кертеп тегегез.

Шул җөйдән 3 мм өстәрәк тагын бер җөй ясагыз. Барлыкка килгән юл буйлап, түбәтәйнең аскы кырые каты торсын өчен, сүс җебе кертегез. Түбәтәй чите әзер (6 рәс.).

Түбәтәйнең биеклеген 8–9 см итеп үлчәп, читенең түбә белән тоташкан урынын ак җеп белән типчеп чыгыгыз. Аскы һәм өске җөйләр арасындагы урынны да, сүс җебе сыярлык киңлектә авыш җөйләр ясап, типчеп чыгарга кирәк (7 рәс.). Сүс җебе калынрак булган саен әйбәтрәк, чөнки түбәтәй формасын саклый, матур тора. Җеп нечкә булса, ул йомарлана торган була. Җеп астан өскә таба үткәрелә. Сапланган камыт энәсен

# Шитьё и простёгивание деталей

Основой тюбетейки являются выполненные вручную тонкие, мелкие стежки. Для придания жёсткости между рядами стежков вдеваются верёвочки типа шпагата.

Шитьё необходимо начинать с нижней части края тюбетейки. Для этого подкладку сложите с бархатной полосой лицевыми сторонами и притачайте на машинке нижнюю часть. Для того чтобы снаружи тюбетейки не торчала подкладка, выверните изделие так, чтобы бархатная ткань на 1–2 мм заходила на изнаночную сторону, и по низу тюбетейки сделайте аккуратный шов.

Отступив на 3 мм от него вверх, сделайте ещё один шов. Для придания жёсткости нижней части убора проденьте шпагат в образовавшуюся кулиску. Надлобная часть готова (рис. 6).

Снизу по лицевой стороне отметьте высоту тюбетейки – 8–9 см и светлыми нитками – линию, по которой будет сшиваться боковая и верхняя часть тюбетейки. Простегайте швом «вперёд иголку» участок, образовавшийся между стежками так, чтобы между ними свободно проходили верёвочки

атлатып тегелгән юл буйлап югарыгы аркылы җеп кертелгән юлга кадәр җиткерегез, энлекне тишеп, энәне тышка чыгарыгыз һәм җепне кисегез. Шулай итеп, түбәтәй читен тулысынча эшкәртеп чыгыгыз. Киселгән җепләрнең очлары күренмәсен өчен, тукыманы җиңелчә генә тартып, аларны эчкә керткәләп җибәрегез.

Тасма әзер булгач, эчлегенең артып калган җирен бөкләп, аның ике башын бер-берсенә ялгап тексәгез, ялгаган җөй күренмәс.

Хәзер түбәтәйнең түбәсен сыру эшенә керешәбез. Бәрхеткә өлге төшерү кыен булганга күрә, аны эчлеккә ясыйбыз. Моның өчен түбә эчлеген алтыга бөкләп, акбур яки сабын кисәге белән сызыклар сызыгыз. Ул сызыклар түбәтәй түбәсен алты тигез өлешкә бүлә. Сызыклар дуга сыман булырга тиеш. Аларны кулдан, йә булмаса, каты кәгазьдән ясалган өлге ярдәмендә дә сызып чыгарга мөмкин. Өлгенең очлы башын түгәрәкнең үзәгенә каратып, туры ягын сызыкларга куеп, алты дуга сыман сызык ясагыз (8 рәс.).

Хәзер эчлекне бәрхетнең сул ягы белән тоташтырып, әйләнәсен типчеп чыгыгыз. Эчлек өстендәге сызыкларны, сүс җебе


(рис. 7). Чтобы тюбетейка лучше держала форму, старайтесь подобрать не очень тонкий шпагат. Иначе она получится неустойчивой и будет мяться. Верёвочки продеваются снизу вверх, начиная от нижнего стежка. Доведя большую иглу со слегка согнутым концом до верхнего стежка, выньте через подклад наружу, отрежьте верёвку. Таким же образом обработайте все ряды между вертикальными стежками. Подтяните ткань так, чтобы торчащие концы верёвок вошли внутрь изделия.


При сшивании концов полосы соедините два последних стежка вместе, чтобы соединительный шов был менее заметен.

Теперь надо простегать верх тюбетейки. Верхний круг тюбетейки необходимо дугообразными линиями разделить на шесть частей. Для того чтобы дугообразные линии получились одинаковые и ровные, сделайте лекало. И каждую часть по отдельности, как и сами дуги, простегайте, проложите верёвочками. На бумажной основе, подставляя лекало к заранее начерченным сторонам шести треугольников, получите шесть дугообразных линий (рис. 8).


Эти линии переведите через копировку на подкладку. После этого подкладку прита-


6 рәс.
Рис. 6





7 рәс.
Рис. 7







сыярлык итеп, бәрхет төсендәге җеп белән сырыгыз. Җепне үткәрү өчен, сапланган энәне түбәнең читеннән дуга сыман юллар буйлап аның үзәгенә кадәр җиткерегез. Эчлекне тишеп, энәне тышка чыгарыгыз, сүс җебен кисегез һәм, тукыманы аз гына тартып, җепнең очын эчкә яшерегез. Барлыкка килгән почмакларны да шулай ук сырып, һәрбер юл аркылы җеп үткәрегез.

чайте к изнаночной стороне верха тюбетейки по намеченному шву. Сначала простегайте все шесть дугообразных линий и проденьте в них верёвочки. Большую иглу с верёвочкой можно вести от края к центру круга по дорожкам, образованным стежками. Проткнув прокладку в центре, выведите иглу, отрежьте нить и, слегка потянув ткань, уберите внутрь торчащие концы. Таким же образом простегайте всю поверхность круга.


## Түбәтәй өлешләрен тегү







8 рәс.
Рис. 8




9 рәс.
Рис. 9

Түбәтәй матур булып чыксын өчен, иң элек түбә әйләнәсен һәм чит тасмасын дүрт тигез өлешкә бүлегез (9 рәс.). Билгеләнгән урыннарны туры китереп, өлешләрне эләктереп куегыз. Типчеп чыккан юллар буйлап өлешләрне сул яктан тегеп тоташтырыгыз. Читнең эчке ягында артып калган эчлеген түбә ягына бөкләп тегегез. Түбәсен күкләгәндә кырыйларны пөхтәләп тегәргә кирәк.

Әзер булган түбәтәйне уң ягына әйләндереп, бераз су бөркеп, калыпка кидереп киптерегез.

Чтобы сшить детали равномерно, верх и боковой околышек тюбетейки разделите на четыре одинаковые части (рис. 9). Соедините детали с изнаночной стороны по намеченным точкам. Притачайте их по ранее намеченным стежкам. Выступающую полоску подклада боковой части подогните за края соединённых до этого частей тюбетейки и аккуратно пришейте.

Затем выверните тюбетейку, внутри слегка опрысните водой, наденьте на специальную форму до высыхания.

## Сшивание частей тюбетейки





Түбәтәй өлешләре.
Детали тюбетейки.



## ЙОМГАК

Халкыбыз үз тарихында олы үсеш юлы үткән зур мәдәни мираска ия. Гасырларга сузылган олы тарихы булган татар декоратив-гамәли сәнгате Шәрык һәм Гареп (көнчыгыш һәм көнбатыш) мәдәниятләре кисешкән урында барлыкка килә һәм дөньяга таралып яшәгән ватандашларыбызны берләштереп тора.

Соңгы вакытта профессиональ, үзешчән һәм халык һөнәрчеләрен берләштергән милли декоратив сәнгатебез күтәрелеш кичерә. Борынгы традицияләребез заманча киемнәрне, интерьерларны бизәгәндә кулланыла. Бүгенге декоратив гамәли сәнгатьтә төрле заманча технологияләр, материаллар кулланыла. Бигрәк тә чигү, киемнәр тегү, зәркән сәнгате, күн мозаикасы, керамика, курчаклар ясауга ихтыяҗ зур. Аларны республикабыздан читтә торучы замандашларыбыз да бик яратып алалар. Күн мозаикасы техникасында башкарылган матур читекләр бүген татар халкының үзенчәлекле бренды булып тора.

## ЗАКЛЮЧЕНИЕ

Татарский народ обладает огромным культурным наследием, прошедшим большой исторический путь развития. Татарское декоративно-прикладное искусство, являясь яркой связующей нитью восточной и западной культур, служит средством единения наших соотечественников, проживающих в разных странах мира.

В последнее время в декоративном искусстве, состоящем из профессионального, самодеятельного и народного творчества, наблюдается заметный подъём. Стало очень актуально использование древних традиций в современной одежде, в оформлении интерьеров. Это искусство охватывает самые современные материалы и технологии изготовления. Особое развитие получили: вышивка, моделирование одежды, ювелирное искусство, техника кожаной мозаики, керамика, изготовление кукол. Предметы татарского декоративного искусства пользуются большим спросом и далеко за пределами нашего края. Яркие сапожки, выполненные в технике кожаной мозаики, и в наши дни являются своеобразным брендом татарского народа.



# ӘДӘБИЯТ
# ЛИТЕРАТУРА


1. Бабушкина Н. В. Золотое шитьё. – М. : Олма-Пресс Образование, 2003. – 62 с.
2. Бикбулатова М. З. Чигәргә өйрән. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1970. – 67 б.
3. Валеев Ф. Х. Орнамент казанских татар. – Казань : Татар. кн. изд-во, 1969. – 203 с.
4. Валеева-Сулейманова Г. Ф., Шагеева Р. Г. Декоративно-прикладное искусство казанских татар. – М. : Сов. художник, 1990. – 215 с.
5. Воробьёв И. И., Бусыгин Е. П. Художественные промыслы Татарии в прошлом и настоящем. – Казань : Татар. кн. изд-во, 1957. – 57 с.
6. Гулова Ф. Ф. Татарская народная вышивка. – Казань : Татар. кн. изд-во, 1980. – 43 с.
7. Завьялова М. К. Татарский костюм. – Казань : Заман, 1996. – 251 с.
8. Золото и серебро казанских татар. – Казань : Заман, 2002. – 160 с.
9. Сергеева Н. Г. Тылсымлы энә. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2001. – 24 б.
10. Сергеева Н. Г. Әбиемнең сандыгы. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1995. – 32 б.
11. Сергеева Н. Г. Гомер агачы = Древо жизни. – Казан : Мәгариф, 2008. – 79 б.

| ЭЧТӘЛЕК | | СОДЕРЖАНИЕ |
|---|---|---|


| | | |
|---|---|---|
| Кереш | 5 | Введение |
| Милли бизәгебез | 7 | Национальный орнамент |
| Бизәк төзелеше | 9 | Построение узора |
| Чигү | 11 | Вышивка |
| Алтын җеп белән чигү | 12 | Золотое шитьё |
| Зәркән сәнгате | 13 | Ювелирное искусство |
| Нәфис керамика | 15 | Художественная керамика |
| Металлны нәфис эшкәртү | 17 | Художественная обработка металла |
| Бизәкләп туку | 19 | Узорное ткачество |
| Күн эшкәртү сәнгате | 21 | Искусство кожаной мозаики |
| Казан сөлгесе | 23 | Казанское полотенце |
| Шәмаил | 24 | Шамаиль |
| Татар костюмы | 26 | Татарский костюм |
| Калфак | 29 | Калфак |
| Калфак тегү һәм чигү | 31 | Изготовление калфака |
| Түбәтәй | 42 | Тюбетейка |
| Түбәтәй тегү һәм чигү | 44 | Изготовление тюбетейки |
| Йомгак | 54 | Заключение |
| Әдәбият | 55 | Литература |


---


Научно-популярное издание

Сергеева Нурзия Гильфановна

МАГИЯ УЗОРА

Казань. Татарское книжное издательство. 2017

На татарском и русском языках

Фәнни-популяр басма

Сергеева Нурзия Гыйльфан кызы

ТЫЛСЫМЛЫ БИЗӘК

Мөхәррирләре Р. Г. Сәлахов, Э. Р. Хөснетдинова
Бизәлеш мөхәррире Р. Х. Хәсәншин
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы С. Н. Нуриева
Корректорлары И. И. Галиева, А. Р. Миңнуллина

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 15.11.2017. Форматы 84 × 108 1/16.
Шартлы басма табагы 5,88. Тиражы 4000 д. Заказ

«Татарстан китап нәшрияты» ТР ДУП.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.
Тел./факс: (843) 519-45-22.
http://www.tatkniga.ru
e-mail: info@tatkniga.ru

Татарстан китап нәшриятының фирма кибетләре:
Казан, Бауман урамы, 19. Тел.: (843) 294-70-50.
Казан, Бауман урамы, 29/11. Тел.: (843) 292-03-18.
Казан, Декабристлар урамы, 2. Тел.: (843) 519-45-13.

Маркетинг бүлеге:
Казан, Декабристлар урамы, 2. Тел.: (843) 519-45-35.

Интернет-кибет:
http://www.tatkniga.ru

«Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.